КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 декабрь г.Казань № 1099

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган Шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 874 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлектә:

4.2 бүлекчәдә:

4.2.1 пунктның дүртенче абзацында «бакчачылык (дача)» сүзләрен «бакча җир» сүзләренә алыштырырга;

4.2.29 пунктның беренче абзацында «бакчачылык (дача)» сүзләрен «бакчачылык» сүзләренә алыштырырга;

4.4 бүлекчәнең 4.4.40 пунктында «бакчачылык (дача)» сүзләрен «бакчачылык» сүзләренә алыштырырга;

4.7 бүлекчәдә:

4.7.1 пунктта «дача хуҗалыгы;» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.7.2 пунктта «дача хуҗалыгы;» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.7.3 пунктта «дача хуҗалыгы;» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлектә:

5.1 бүлекчәнең 5.1.4 пунктындагы беренче абзацта «Бакчачылык, яшелчәчелек берләшмәләре, дача хуҗалыклары» сүзләрен «Коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек ширкәтләре, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыклары алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар»;

5.2 бүлекчәдә:

38 таблицаның «Җир кырыеннан алып ераклык, метр, ким түгел» графасында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре» сүзләрен «коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре» сүзләренә алыштырырга;

64 таблицаның «Бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциячел булмаган иптәшлекләре, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыклары алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар | 10 участок | 14 | 19»; |

5.3 бүлекчәнең 5.3.128 пунктның сигезенче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек ширкәтләре, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыклары алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләренә алыштырырга;

6 бүлектә:

6.1 бүлекчәнең 6.1.7 пунктында «гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләре» сүзләрен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләре» сүзләренә алмаштырырга, «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.11 бүлекчәнең 84 таблицасында «Түбән Кама» милли паркы (федераль әһәмиятәге)» юлында «Махсус саклау режимы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Милли парк территориясендә табигать комплексларына һәм үсемлек һәм хайваннар дөньясы объектларына, мәдәни-тарихи объектларга зарар китерергә мөмкин һәм милли парк максатларына һәм бурычларына каршы килә торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;

туфрак катламын һәм чыгып яткан урыннарны бозуга китергән эшчәнлек;

гидрологик режим үзгәрүгә китерә торган эшчәнлек;

милли парк территориясендә бакчачылык һәм яшелчәчелек җир кишәрлекләрен бирү;

магистраль юллар, торба үткәргечләр, электр тапшыру линияләре һәм башка коммуникацияләр төзү, шулай ук хуҗалык һәм торак объектларын төзү һәм файдалану, туристлык индустриясе, музейлар һәм мәгълүмат үзәкләре, милли паркның эшләве һәм аның чикләрендә урнашкан торак пунктларның эшләвен тәэмин итү белән бәйле объектлардан тыш;

үзагач әзерләү (гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен әзерләүдән тыш);

чәер әзерләү;

һөнәрчелек, спорт һәм үзешчән ау;

сәнәгать һәм яр буе балыкчылыгы;

ашарга яраклы урман ресурсларын (азык-төлек урман ресурслары), башка агач булмаган урман ресурсларын әзерләү (гражданнар тарафыннан мондый ресурсларны үз ихтыяҗлары өчен әзерләүдән тыш);

хайваннар һәм үсемлек дөньясы объектларының яшәү шартлары бозылуга китерә торган эшчәнлек;

биологик коллекцияләр җыю, «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең фәнни тикшеренү темалары һәм планнары белән каралган фәнни-тикшеренү эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырыла торганнардан тыш;

тере организмнарның акклиматизациясе максатларында аларның интродукциясе;

йорт хайваннарын уртак кулланылыштагы юллар һәм су юлларыннан читтә һәм моның өчен махсус каралган урыннардан читтә көтү;

агымсулар һәм сулыклар буенча агач агызу;

махсус каралган урыннардан читтә массакүләм спорт һәм тамаша чараларын оештыру, туристлар тукталышларын оештыру һәм учаклар ягу;

үз белдеге белән археологик казулар алып бару, тарихи-мәдәни кыйммәткә ия предметларны җыю һәм чыгару;

ату, пневматик һәм ыргыта торган корал белән, шул исәптән корылган рәвештә аучылык ату коралы белән, капканнар һәм башка ау кораллары белән, шулай ук хайваннр дөньясы объектлапрын тоту продукциясе һәм су биоресурсларын тоту кораллары белән уртак кулланылыштагы юлларда булу, Россия Федерациясе Табигать байлыклары һәм экология министрлыгының «Түбән Кама» милли паркы» турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 10 май, 285 нче боерыгы белән расланган «Түбән Кама» милли паркы» турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) нигезендә милли парк территориясен саклау һәм файдалау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча вәкаләтле затлар тарафыннан чаралар үткәрү белән, спорт һәм үзешчән балыкчылыкны гамәлгә ашыру белән бәйле очраклардан тыш;

шартлату эшләре;

янгыннар җибәрү, үсемлекләр яндыру («Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп гамәлгә ашырыла торган янгынга каршы чаралардан тыш);

урманнарны тоташ кисү, урман янгыннарын сүндерү белән, шул исәптән янгнга каршы өзүләр ясау белән бәйле тоташ санитар кисүләрдән һәм Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла торган линея объектларын төзү, төзекләндерү һәм файдалану белән бәйле кисүләрдән тыш;

җитештерү һәм куллану калдыкларын, радиоактив, химик, шартлаткыч, токсинлы, агулаучы һәм агулы матдәләр урнаштыру объектларын трөзү, Нигезләмә нигезендә җитештерү һәм куллану калдыкларын җыюдан тыш;

су объектлары ярларында транспорт объектларнын юу;

уртак кулланылыштагы юллардан һәм махсус каралган урыннардан читтә механикалаштырылган транспорт чаралары хәрәкәте һәм тукталышы, уртак кулланылыштагы су юлларыннан һәм махсус каралган урыннардан читтә суднолар һәм бүтән йөзүче чаралар хәрәкәте һәм тукталышы (милли парк эшләве белән бәйле очраклардан тыш);

милли парк территориясендә аншлагларны, шлагбаумнарны, стендларны, чик баганаларын һәм башка мәгълүмат билгеләрен һәм күрсәткечләрен, җиһазландырылган экологик сукмакларны һәм ял итү урыннарын, корылмаларны юу итү һәм зарарлау, зур ташларга, ачык тау токымнарына һәм тарихи-мәдәни объектларга язулар һәм билгеләр төшерү;

җирләрне сукалау (урманнарны янгынга каршы җиһазлау һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен милекчеләре, хуҗалары һәм кулланучылары тарафыннан кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш);

үсемлекләрне саклау өчен ядохимикатлар, минераль ашламалар, химик чаралар һәм үсеш стимуляторлары куллану (авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен милекчеләре, хуҗалары һәм кулланучылары тарафыннан кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш);

этләрне бәйсез, вольерлардан яки аларның хәрәкәтен чикли торган бүтән корылмалардан читтә тоту, этләрне өйрәтү»;

«Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы (төбәк әһәмиятендәге)» юлында «Махсус саклана торган табигать территорияләре категорияләре» графасының унөченче абзацында «дача» сүзен «бакчачылык» сүзенә алмаштырырга;

7 бүлекнең 7.4 бүлекчәсендәге 7.4.16 пунктның беренче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләре» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциячел булмаган берләшмәләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына 1 нче кушымтада:

«Федераль законнар» бүлегенең 24 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 271-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Берләшкән Милләтләр Оешмасының һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив актлары» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 28 пункт өстәргә:

«28. Россия Федерациясе Табигать байлыклары һәм экология министрлыгының «Түбән Кама» милли паркы» турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 10 май, 285 нче боерыгы;

әлеге шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына 3 нче кушымтада:

V бүлекнең 4 таблицасындагы «Сәүдә объектлары, шул исәптән: киосклар, павильоннар, кибетләр, сәүдә үзәкләре, сәүдә комплекслары» юлының 6 графасында «бакчачылык һәм дача берләшмәләре» сүзләрен «бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциячел булмаган берләшмәләре, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыклары алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләренә алыштырырга.

2. Бу карар, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә торган 1 пунктның унтугызынчы – кырык сигезенче, илле дүртенче, илле алтынчы абзацларыннан тыш, 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин